Ничек итеп Патша Чыпчык белән дуслашкан?

Борын – борын заманда яшәгән ди бер усал Патша. Аның хезмәтчеләре аннан куркып торганнар ди.
Язлар җитеп, чәчүләр чәчкәч, уҗым тишелеп чыккан. Шифалы яңгырлар явып, кырларда икмәк күкрәп үскән. Менә шул вакыт Патша кырга чыккан. Ни күрсен: икмәк өстеннән көтү- көтү булып чыпчыклар оча икән. Патшаның моңа бик ачуы килгән.
Хезмәтчеләрен җыйган да әмер биргән. Барлык чыпчыкларны да тотып, үтереп бетерегез дигән. Хезмәтчеләр ничек итсәләр иткәннәр, барлык чыпчыкларны һәм аларның балаларын юк иткәннәр.
Шулай уңышны җыеп алганнар...
Яңадан язлар килгән...Чәчүләрне чәчкәч, Патша тагын үз җирләрен карап йөререгә чыккан. Чыкса, ни күрсен: икмәк кырында төрле бөҗәкләр мыжгылдап тора икән.Патша аптырашта калган.
Бу елны илдә икмәк булмаган. Ашар өчен икмәкне күрше патшалыктан сатып алырга туры килгән. Ипи белән бергә Патша чыпчыклар да сатып алган.
Шуннан соң Патша кошлар белән дуслашкан. Икмәге дә уңган, үзе дә акылга утырган , ди.

Заһидуллин Илдар, 5 а сыйныфы.